БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 март 2026 ел № 43

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17 (1) статьяларына һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 26 февралендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2016 елның 23 декабрендәге 68 номерлы карары (Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2017 елның 24 июнендәге 88 номерлы, 2018 елның 1 ноябрендәге 151 номерлы, 2020 елның 9 октябрендәге 10 номерлы, 2022 елның 18 январендәге 100 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 186 номерлы, 2023 елның 9 августындагы 204 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 227 номерлы, 2024 елның 7 августындагы 267 номерлы, 2025 елның 17 декабрендәге 27 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 14 бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

«14. Керемнәр, чыгымнар турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру

14.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган белешмәләрне әлеге Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшыра. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән

тәртиптә, срокларда һәм формада күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан тапшырыла.

14.2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль закон) каралган чыгымнар хакында белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртип һәм форма буенча тапшырырга тиеш.

14.3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, әлеге Кодекста, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) норматив хокукый актларында каралган тәртиптә муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

14.4. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр, әгәр федераль законнар тарафыннан дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр була.

14.5. Муниципаль хезмәткәрнең әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрен муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү сәләтен билгеләү яисә ачыклау өчен, дини яисә башка иҗтимагый берләшмәләр, башка оешмалар, шулай ук физик затлар фондына турыдан-туры яисә читләтелгән рәвештә иганәләр (взнослар) җыю өчен файдалану рөхсәт ителми.

14.6. Әлеге статья нигезендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне ачуда яисә әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында каралмаган максатларда куллануда гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

14.7. Муниципаль хезмәткәрнең «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакындагы белешмәләрне, мондый белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булып та тапшырмавы, йә белә торып тулы булмаган белешмәләр тапшыруы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач район Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин